ISSN 0136-7110

# ЧАЯН




САТИРА
һӘМ ЮМОР
ЖУРНАЛЫ

23

СКОРПИОН * SCORPION

ДЕКАБРЬ 2015 * КАЗАН



Николай ВОРОНЦОВ

Ринат АБЗАЛОВ

# АННАН-МОННАН ИНФОРМ

## СОҢГЫ ХӘБӘРЛӘР

Рәсәйнең Хәрби-космик көчләре Нобель премиясенең тынычлык номинациясенә тәкъдим ителгән.

Рәсәйнең Тышкы эшләр министрлыгы, рус-төрек мөнәсәбәтенең иң яхшы дипломаты дип А. В. Суворовны таныган.

Украинада, Ленин һәйкәлләрен җимереп бетергәннән соң, баганаларны аударырга керешкәннәр.

Фәлсәфи җәмәгатьчелек аптырашта: ни өчен дальнобойщиклар Платонга һөҗүм итә башладылар?

Израильдәге махсус хезмәт органнары Ребе Гудны тоткарлаган. Ул байларның акчаларын бик аз процентка ярлыларга тараткан.

"Турецкий хор" җитәкчесе фамилиясен үзгәртергә тели.

Украина армиясенә бронядан тегелгән түшлекләр, каккычлар таратылган.

Великие Грязи шәһәренең мэры, Крымга дуслык мөнәсәбәтендә, үзенең шәһәрендә электр һәм җылылык бирүне туктаткан.

Уң яклы руль куелып, "Уссурийский тигр" БТРы махсус Ерак көнчыгыш хәрби округы өчен чыгарылган.

Язучы Дарья Концованы коллар сатуда гаеплиләр. Аның фатирында унлап әдәби негрның барлыгын ачыклаганнар.

Табиблар кисәтә: урина белән дәвалану энурезга китерә!

Илебез спортындагы химия һәм допингны тамырдан бетерү өчен борынгы ысулларга әйләнеп кайту кирәк – экологик яктан чиста чебен гөмбәсенә.

Иң сентименталь китап дип Г. Фихтенгольцның "Интеграл һәм дифференциал исәпләү" китабы саналган. Ул – берничә буын кызларны еларга мәҗбүр иткән әсбап.

Һиндстан судында бер адвокат шулхәтле шәп биегән ки, шул сәбәпле, гаепләнүче хәтта гаепсез дип танылган.

Сәнгать белгечләренең ачышы: К. Малевичның "Кара квадрат"ы шушы вакытка кадәр асты өскә каратып куелган булган икән.

Район хастаханәсендәге бер авыру, травматологка чиратсыз керергә маташып, туп-туры реанимациягә эләккән.




## ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР

Үзеңә ышанган кебек ышанган хатынга беркайчан да ышанырга ярамый.

Хатын-кызларны үзебезнең бөтен җитешсезлекләребез белән кабул итәргә кирәк.

Хатын-кызга бары тик ул алдаган очракта гына ышанырга була.

Әгәр дә хатын-кыз нәрсә теләгәнен белми икән, димәк, ул сине теләми.

Чибәр, бай һәм акыллы хатыннар чибәр, бай һәм җүләр ирләрне артык күрәләр.

Хатын-кыздан акылыңны югалту – хатын-кыздан башка акыллы булып калудан хәерлерәк.

Ирләр хатыннардан акыллырак, тик ахмак хатыннар аларны барыбер алдый.

Аяклар – хатын-кызның йөзе.

**(Зыялылар мәҗлесендә язып алынды)**

Александр СЕРГЕЕВ






Хөрмәтле Чаян! Яхшы законнар бездә җитәрлек кабул ителгән. Ә менә аларны үтәү-үтәмәү беркемне дә кызыксындырмый, ахрысы. Мәсәлән, алкогольле эчемлекләр бары 21 яше тулган кешеләргә генә сатылырга тиеш. Ә күптән түгел кибеттә минем күз алдында яшүсмер бер шешә шәраб сатып алды. Сатучының исе дә китмәде...

**А. ГАБДРАХМАНОВА**

ӘГЕРҖЕ

**– Бәлки, ул кайчандыр әти-әнисе белән Ерак Төньякта яшәгәндер? – дип фаразлады Шомбай ага. – Ә анда бер ел өчкә бара бит...**

**Александр АЛЁШИН**




**Искәндәр БОРҺАНОВ**

## Дарвин буенча

Бу телевизор дигәннәре тапшырулары белән эчне пошыра һәм холыкны боза. Бердәнбер карарлык нәрсә – хайваннар турында тапшырулар...

Уйлап карасаң, алары да...

Менә, маймыллар, куллары эләктерергә генә тора, ришвәтчеләрнеке кебек...

Крокодилның тешләре – бакирныкы кебек комсыз, ыржаеп тора...

Әрләннәр – чиновниклар кебек, гаҗәпләнгән күзләр белән тораташ катканнар, ә үзләре күбрәк булсын һәм озаккарак җитсен, дип, яңак артын тутыралар.

Жирафлар – олигархлар шикелле, каяндыр өстән дөньяны күзәтәләр...

Арысланнар да, чираттагы корбанын ашаганнан соң кебек, кикерә-кикерә, хакимнәр сыман йокымсырагап бушлыкка карап утыралар...

Яшьләр, бүре-шакаллар кебек, кайда нәрсә эләктерергә булыр микән, дип, каранып йөри...

Каядыр идән ярыгына посып, соры тычкан кебек утырасы килә...

Бу дөнья белән нәрсә эшләп була соң? Бөтенесе дә Дарвин буенча бит!

**Виктор БОГОРАД**



# ЯБЫК АЧЫК МОХИТ

Колакка сак кешеләр мине гафу итсен – «Ачык мохит» программасы турында чукраклар гына ишетмәгәндер. Ләкин йөз кат ишеткәнче бер кат күрү яхшырак, диләр бит. Мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрнең көнкүреш проблемаларының ни дәрәҗәдә мөһим булуын Татарстан буенча үткәрелгән рейдта социаль хезмәткәрләре үз күзләре белән күрергә булган.

Алабуганың үзәк район хастаханәсе. Беренче карашка, монда инвалидларны истә тоталар кебек. Бусагадан ук ялтыравык тоткалы пандуслар күзгә ташлана. Ләкин керү белән уңайсызлыклар башлана. Дәвалау учреждениесенең ишекләре бик тар – аның аша инвалид коляскалары уза алмый. Мондагы бәдрәфләр дә колясkada йөрүчеләр өчен яраклаштырылмаган. Унитазга, гафу итегез, ни утырып, ни торып булмый. Палаталарда медицина персоналын чакыру төймәләре эшләми. Монысы инде алабугалыларның гына бәласе түгел. Бөгелмәдә дә шул ук хәл – палатадан табиб чакыру Бөгелмә район хастаханәсендә дә, җирле балалар клиникасында мөмкин нәрсә түгел. Балалар клиникасы, гомумән, инвалидлар кабул итүгә яраклаштырылмаган.

Ә менә Чаллы шәһәренең инфекция хастаханәсендә чакыру төймәсе бар. Аның хәтта звоногы да эшли! Дөрес, кем өчен эшләве аңлашылмый. Чөнки хастаханәнең санитария-гигиена бүлмәсе «Ачык мохит» авыруларын кабул итү өчен көйләнмәгән. Балык Бистәсендәге дәвалау оешмасы да бик яхшы хәлдә түгел – бүлмәләрдә күтәргечләр һәм тоткалар юк. Кыскасы, килеп җитә алсагыз, рәхим итегез!

Республика башкаласы бу өлкәдә үрнәк булырга тиеш кебек. Ләкин монда да мөмкинлеге чикләнгән кешеләр өчен бар да уңай дип әйтү кыен. Җәмәгать урыннарында, китапханә, парикмахерская, кибетләрдә алар үзләрен бик уңайсыз тоя. Кечкенә генә мисал: Ямашев проспектындагы парикмахерскаяга керү урынында пандус бар да шикелле, ләкин аның күтәрелү почмагы шундый итеп ясалган ки, аннан альпинист тәҗрибәсе булган сәламәт кеше генә менә ала.

Тагын да ямансурагы – җир өстендәге җәяүлеләр өчен кичүләрнең күтәргеч-лифтлары турында. Казанда алар теләсә кем өчен ачык, бары тик инвалидлар өчен түгел. Эшли торган лифтларны санау өчен ике бармак җитә, чөнки миллион кеше яшәгән шәһәрдә алар бары тик икәү – Ветеринария институты тукталышында. Калганнары йә йозакта, йә җимерек хәлдә. Карбышев һәм Комаров урамнарындагы күтәргеч-лифтлар исән, чөнки аларның куелганнан бирле эшләп караганнары юк.

Мондый мисалларны тагын һәм тагын китерергә була. Рейд барышында без дистәләгән мисалларга тап булдык. «Ачык мохит» бар барын, ә меңләгән инвалидлар өчен ул ябык булып чыга...

**Артём СУББОТКИН**









**Рашат Низами:**
Сугышта җиңүчеләр булмый, корбаннар һәм тираннар гына була.

**Алмаз Хәмзин:**
Сугышта җиңүчеләр бар барын,
Ләкин җиңгәч, шәрран яралар...
Җиңелүчеләре, күп очракта,
Яхшы, матур тормыш коралар.
Сугыш бит ул ахмаклыкның чиге,
Шул ахмаклык ясый корбаннар.
Ахмак патша, ахмак император –
Тиран булып халкын кыралар.

**Рашат Низами:**
Оппозициядә булу өчен белем һәм тәҗрибә генә түгел, батырлык та кирәк.

**Алмаз Хәмзин:**
Булса иде гадел җәмгыятьләр,
Булса иде гадел хөкүмәт!
Кеше яшәр иде хөр, рәхәт!
Барысы да хакимлеккә ыргыла,
Барысына алтын тәхет кирәк.
Оппозицион блоклар оеша,
Алдап, рәхәтлек, бәхет теләп.

**Рашат Низами:**
Теләсә кайсы милли рәнҗеш тора-бара милли идеягә әверелә...

**Алмаз Хәмзин:**
Иң рәнҗешле милләт бездер әле,
Бездер әле иң нык изелгән?
Безнең сабырлыкка тиңнәр бармы,
Аңлатып булмаслык сүз белән?
Рәнҗеп ята татар “теге” чорга,
Үпкә тота руска, җиңелгәч.
Ачу саклап йөрмә, башың сакла,
Җиңәрсең, миеңә аң кергәч!..









## ГАРМУНЫҢНЫ УЙНАП ҖИБӘР!

Огайо штатының Цинциннати шәһәрендә консерватория тәмамлаган Пол Уолтер үзенең диссертациясен... татар гармунына багышларга булган. Моның өчен аңа җиде төрле халык гармунында уйнарга өйрәнергә, татар телен үзләштерергә һәм республиканың берничә районына экспедициягә чыгарга туры килгән. Безнең галимнәр америкалының татар музыкасы өстендә тикшеренуләренә югары бәя биргәннәр. Хәзер океан артында да безнең гармуннар күрекләрен җәеп җибәрер дип өметләнә алар.

## ЯБЫКЛАРГА – ПРЕМИЯ!

Кемерово өлкәсе башлыгы Аман Тулеев ябыгырга булган кешеләрне куәтләргә булган. Кимегән килограммнар өчен ул... ташкүмер белән премия өләшергә уйлый. Губернаторның әйтүенчә, ул моны Дубаи практикасыннан үрнәк итеп алган. Анда хакимият һәр кимегән килограмм өчен бер грамм алтын биреп бара икән. Кузбасста исә вакланып тормаска булганнар һәм күмерне граммлап түгел, ә тонналап таратырга карар кылганнар. Ябыгучы бөтен кешегә дә күмер җитәрме, юкмы, анысын инде шахталардан чыгарылган файдалы казылманың күләме күрсәтер.

## МОДАЛЫ КОРСАК

Физик яктан камиллек идеалларына омтылыш модадан чыккан. Зур корсаклы ирләр тынычлана алалар: аларның «сыра бүксәләре» хәзер ихтирам ителә. Америкалы Маконзи Пирсон яңа мода уйлап тапкан һәм аны «Ded Bod» (Аталар тәне») дип атаган. Беренчеләрдән булып яңа башлангычны, шатланып, эстрада һәм кино йолдызлары эләктереп алган. Алар үзләрен, сирәк-мирәк спортзалга йөреп, кичке аш вакытында бер-ике кружка сыра эчеп куючы ирнең ягымлы тәне хатын-кызлар өчен сөйкемлерәк булуы белән юаталар. Дөрес, «модалы корсак»ның төгәл зурлыгы искә алынмый.




БАШЫҢА ҖИТӘР...

Валентин ДРУЖИНИН



Виталий ФЕОКТИСТОВ





Виктор ФЁДОРОВ

## Юлдан язу

Чистайда ике дусның очраклы очрашуы алар көтмәгәнчә тәмамланган. Берничә ел очрашмаган егетләр бу вакыйганы бик шәпләп билгеләгәннәр. Кич тын һәм аулак булырга охшамаган, һәм дуслар туган шәһәрләре буенча сәяхәт кылырга булган. Машиналары булмау аларны аптырашта калдырмаган. Куып алып киткән машинаның беренчесендә кинәт бензин беткән. Икенчесен кабыза алмаганнар. Өченчесе бар таләпләргә дә туры килгән, һәм алар шәһәр буенча туйганчы куып арыганнан соң, машина эчендә йоклап ук киткәннәр. Иртәгесен аларны полицейскийлар уяткан.

Хәзер машина куучыларны суд хөкеме көтә. Дусларга тагын кайчан очрашырга язгандыр – моны бары судья гына белә...

Илдар ИБРАГИМОВ

Михаил ЛАРИЧЕВ




• • •

**– Син Яңа елны каршы алырга җыенасыңмы?**
**– Хәтерләмим! Исерек булачакмын!**

• • •

**– Эштәге мәҗлестән кайтып килән, кинәт арттан кычкыралар:**
**«Тукта! Тик тор!».**
**– Ә син?**
**– Кая, ди, ул тору, үрмәләвем дә көч-хәл белән...**



## Мәзәк өстенә мәзәк

• • •

Урам буйлап бер әби бара, шулчак аны бер егет узып китә. Әби кеше аның артыннан кычкырып:

– Егеткәй, син сберкассагамы?
– Әйе.
– Чиратта минем арттан булырсың.

• • •

Туристлар кеше ашаучылар кулына эләгә. Башлыклары әйтә:

– Кем дә кем яңа мәзәк сөйли – шуны җибәрәбез. Кисәтеп куям – бездә Интернет бар!

• • •

Иренең күрше кызына өйләнәчәген белгәннән соң, хатыны аннан ачуын алырга ниятли: шул күрше кызының әтисенә кияүгә чыгып, иренә кайнана була.

• • •

Оныгы бабасыннан сорый:
– Бабай, син яшь чакта кайда утырдың: контакттамы әллә классташлардамы?
Бабасы:
– Мин, классташ кыз белән контактта булу сәбәпле, маймыллыкта утырдым.

• • •

Бик мәдәниятле булып кыланып йөргәннәрне җаным сөйми. Үзләре Моцарт турында сөйләшәләр, ичмасам, берәр картинасын күрсәтсәләр иде шуның!

• • •

Армиядә.
– Иптәш прапорщик, телевизор карарга ярыймы?
– Кара, ләкин кабызма.

• • •

– Балакаем, йөткергән вакытта авызыңны учың белән капларга кирәк.
– Әбекәем, курыкма, минем тешләрем синеке кебек очып чыкмаячак.

• • •

– Соңгы елларда "кайнана-кияү" темасына кызык мәзәкләр чыгару шактый кимеде. Бу – сәер хәл...
– Нинди кызыклар булырга мөмкин? Бөтен гаиләбез белән кайнанабыз пенсиясенә яшибез!

• • •

– Сезгә сокланырлык! Өйләнешүегезгә 20 ел булуга карамастан, сез һаман култыклашып йөрисез.
– Әгәр мин аны кулымнан ычкындырсам, ул берәр нәрсә сатып алырга чабачак бит.

Александр СЕРГЕЕВ




Александр ФИЛИППОВ

## ИКЕЙӨЗЛЕЛЕК

Алдар тазлар чыкты аренага
Күз дә йоммый ялган таратып,
Кәмитчеләр хәзер драма уйный
Халык күзен күккә каратып.

Бер аллага ышан син, аллага,
Барыр юлың бары шунда, дип,
Дәһриләр дә тәкбир әйтә хәзер,
Тәкъдирендә шулай язган бит.

Танымассың инде күршеңне дә,
Әллә битлек, әллә үз йөзе.
Кояш баеп йолдыз кабынгач та
Кара төскә керә күк йөзе.

Ике йөзле булу җиңелдер ул,
Бер төкерсә шайтан битенә.
Илең өчен түгел, көнең өчен
Аяк асу дөнья читендә.



Илдар НӘФИЕВ

Лиана МӘРДАНОВА

## АКЫЛЫ АЛТЫН ИКӘН...

Беләсеңме, ахир, хатын-кызда иң мөһиме нәрсә? Фигурасы! Чибәрлеге! Урыс әйтмешли, самое важное в женщинах – красота! Хатыныңның йөзе кояш кебек балкымаса, сары чәчләренең дулкынлануы күңелеңне назламаса, зифа гәүдәсенең сихри силуэты дөньяңны оныттырып үзенә тартып тормаса – өйләнүенең ни кызыгын табасың?!. Ул, парлашып, кеше көнләштереп кунакка барулар! Ул чит илләргә сәяхәт кылып кайтулар! Франция, Италия, Испанияләрдә йөрүләр. Диңгездә, океаннарда коенып, хатыныңны чем-кара итеп кызындырулар! Монда кайткач, кеше кызыктырулар! Ах, ахир! Син шуны аңлыйсыңмы? Аңламыйсың шул син. Хатын-кыз ул машина түгел, аны җүнләп ухаживать итәргә кирәк. Гел гүләйт итеп тә йөреп булмый. Аның бит бала табасы да бар. Матур кешедән матур бала туарга тиеш. Садикка илткәндә кеше: "Карале, моның баласы нинди ямьсез икән", – дисә, җир тишегенә кереп китәрдәй булырсың бит. Мин, ахир, үземчә хәл иттем: кызлар белән танышыр алдыннан бөтен җирләрен тикшереп чыгам: теге төше нинди, бу төше нинди, аяклары камыт түгелме, чибәрлеге... Әлбәттә, чәчләренә игътибар итәм, иреннәре мөлдерәп пешкән чия төсле булсын!.. Аш-суга осталыгын чамалау да комачауламас. Шуннан соң гына туп-туры ЗАГСка!

Автобусның арткы рәтендәге ике утыргычка көчкә сыйган бер центнерлы Айрат, ахиренең теңкәсенә тиеп, 43 яшендә беренче мәртәбә туйга әзерләнгәндә нинди кыз сайлаячагын аңлатып, киләчәккә планнарын сөйли иде. Әйе, метр ярым буйлы, әлегә хәтле өйләнмәгән егетнең акылы алтын икән дә бит! Ләкин өйгә кайткач, гел диванда аунавы, машинасы да булмагач, эшкә автобуста гына йөрүе бу хыялларның буш хыял гына булып калуына ышанасың.

"Авыш баганага терәү ошый" дигән мәкальгә таянып уйлансак, бәлки, Айратка да шундыйрак – үзе төслерәк терәк табу кулайрак булыр.




Виталий ПОДВИЦКИЙ

# “Чаян” кунекмәсе

ЙӨЗ УТЫЗ ӨЧЕНЧЕ ТУР



Әллә нинди куркыныч уйлар килә бу әбинең балта тоткан халәтенә карап. Кая бара, нишләп шундый хәсрәткә баткан ул? Әйтерсең лә, әлеге шомлы аллея буйлап соңгы адымнарын атлый әбекәй. Ярый әле җәһәннәмгә барган җиреннән яки кемнедер шунда озатырга уйлаган мизгелендә безгә борылып карамый ул – йөзен күрсәк, йөрәгебез тибүдән туктар сыман... Әлбәттә, бу рәсемдә җәмгыятебезнең шушы катлам кешеләренә булган мөнәсәбәте ачык чагыла сыман. Галимҗан Ибраһимов сыманрак **“Татар әбисе ниләр күрми...”** диярсең. Хәер, кем нәрсә уйлыйдыр бу рәсемгә күз төшереп?.. Безнең бурыч, кунекмәгә килгән “тёрттермәләрне” сезгә, хөрмәтле укучыларыбыз, ничек бар шулай җыйнап бирү.

**“Телеэкранга “Җинаять һәм җәза” романы яңача төшерелеп күрсәтеләчәк”**, – дип, Азнакайдан А. Әхмәтова үзенчә анонс биргән. **“Дом-2”ны кайдан табып була икән? Бөтенесен туздырыр идем...”** дигән уйдырма фикер кертеп, Чаллыдан Д. Насыйров телевизион версияне башкачарак киңәйтеп җибәрә. **“Миңа кредит биргән банкир шушыннан үтә диделәр”**, – дип, Түбән Камада яшәүче И. Гайсин бу әбине “Халык герое” ролендә күрә. Хабаров краендагы Санболи бистәсе кешесе С. Коняшеваның **“Олы юлга чыккан...”** – дигән уй-фикере дә әбекәйнең халәтенә туры килә. **“Пенсиясенә өстәмә сорарга чыккан”**, – дип Пермь краеның Губаха шәһәрендә яшәүче А. Летов та пенсионерларның гомуми таләбен, гомер кичерүчеләрнең барлык төбәкләрдә дә бертөрле үк түбән икәнлеген чагылдыра. **“Безнең пенсия акчасына боткаНы шул балта белән пешерсәк кенә инде”**, – дип, Баулыдан В. Фәйзрахманова әлеге теманы кайнарлатып җибәрә. **“Картлыгы аны өйдә каршыламас!”** – менә шулай дип, казанлы В. Чопорнов рус җырыннан өзек китергән. **“Хәзерге заманда паркка балтасыз чыгалармы соң, җүләр?..”** Тагын бер казанлы Рәхимовның шаяртуына төзәтмә яки аңлатма бирүне кирәк тапмыйбыз. **“В бой идут одни старики”**, – монысы Җәлил бистәсендә яшәүче Д. Моисееваның шул исемдәге кинодан алган фикере. (**“В бой идут одни старухи”** дип төзәтеп әйтәсе килә). **“Әҗәл ролендә – әби”**, – Әлмәттәге Г. Хәйруллин иптәшнең фантазиясе. Ә менә Зәй шәһәрендә яшәүче, “Чаян”ыбызны яратып даими укып баручы Гыйззәтуллин якташы – язучы Аяз Гыйләҗевның атаклы романы исеме белән җавап биргән: **“Балта кем кулында?”** Димәк, без шуның әсирләре.

Бу төртмә кисәтү безне сискәндереп куйды. Менә бит “кунекмә”ләр нинди уйларга китерә? Чынлап карасаң, бар монда хикмәтләр!.. Балта әби кулында бит! Без кайда соң, егетләр?..






Николай ВОРОНЦОВ



Никифор ТУКМАЧЁВ

## ЯШЬ ШАГЫЙРЬЛӘРГӘ

Башлап шигырь язганнарга
Бер генә киңәш бирәм.
Язарга өйрәнү – җиңел.
Ничек язмаска өйрән!

Китабың чыккач, каләмне
Тотсаң да кыюырак;
Ничек язмаска өйрәнү
Барыбер кыенырак.

Илдар НӘФИЕВ

Нажия БӘХТИЕВА

# СӘГАДӘТ

Сакаллы классиклар фикеренчә, дин ул халык өчен әфьюн, агу. Нинди әфьюн булсын инде ул? Үлән инде... Ә менә Интернет – файдаланучылар өчен чын әфьюн, наркотик!

Элек кешеләр яхшы, ләкин томана булганнар. 1825 елның декабрен генә искә алыйк. Интернет булганда тарих шундый борылыш ясар идемени? Биш блогер – Пестель, Рылеев һәм башкалар үзләренең сайтларында сорашу оештырган булырлар иде.

– Иминлек Берлегенә кушылыгыз!

– Коткару Союзына кушылыгыз! Бонуслар алыгыз һәм дусларыгызны чакырыгыз!

Бөтен социаль челтәрләрдә изаланган крепостной крестьяннарның фотолары һәм язулар – «әгәр класс куймасаң – синең йөрәгең юк!» Социаль сорашулар – «Кем Николай I гә каршы?», «Кем крепостной правога каршы?». Класс куябыз – һәм безнең күпме икәнебезне беләбез. Ә ахырда – Сенат мәйданында флэшмоб. Биш минуттан бөтенесе таралыша. Бернинди канлы җәзалаулар, асып үтерүләр, сөргеннәр юк!

Ә мәшһүр А. С. Пушкин? Дантесны кара исемлеккә керттең, дуслар исемлегеннән чыгардың, фотосына кара тап куйдың – вәссәлам, бернинди дуэль да юк. Ә шагыйребез «Стихи.ру»га тагын күпме гүзәл иҗат җимешләре куйган булыр иде!

Ә без андый түгел! Хәзер без кыю. Шундый комментарийлар язабыз – чыда гына хакимият! Йоклап утырган депутатларның фотографияләре астына нинди тәрткеләр язабыз! Хайваннарны Интернетта гына асрыйбыз. Нигә бушка көч түгәргә – кытайлар барыбер туйдырырлар да, киендерерләр дә. Тиздән сайлауларда тавыш бирү дә Интернет аша гына булачак, ди. Тизрәк булсын иде инде...

Җан тыныч, бөтенесе дә өйләрендә утыра, бар нәрсә дә контрольдә. Сәгадәт!






Игорь ЛЕВИТИН

# ШӘХЕСЛӘР ҺӘМ ШӘРЕХЛӘР

## АХИР ПРЕМИЯСЕ

Каядыр кәеф-сафа корып, күңел ачып яткан Ркаил Зәйдулла язучы Хәбир Ибраһимга, Ахирга шалтырата. "Карале, Ахир, син мине машинаң белән Аккош күленә илтеп куй әле, су керәсе килеп китте!" – ди бу. Ахир, гадәттәгечә, ык-мык килә башлый. Шунда шалтыратучы: "Фатих Хөсни премиясен аласыңны да онытма!" – дип өстәп куя. Сөекле хатынының җылы кочагында изрәп, Аккош күленә түгел, бәдрәфкә барырга да иренеп яткан Хәбир Ибраһим фәлсәфә чәчәргә тотына: "Нишлим мин аны алып? Тиздән Ахир премиясе булачак, ала алырсыз микән?" Тукай, Җәлил, Хөсни, Бурнаш һәм хәтта Дамир Сираҗи премияләренә ия булган күренекле шагыйрь шундый сүз ыргыта: "Алырбыз ансын да, бездән калмас!"

## ӘТИНЕ САТМЫЙМ!

Ркаил Зәйдулла бервакыт Хәбир Ибраһимнарга ияләшә. "Минем бер җүнле дус калмаган, чын дустым ул син икән!" – дия-дия, аңа кунакка кайта. Ике бүлмәле фатирның гомер ремонт күрмәгән аш ягында, матур әдәбият турында сөйләшә-сөйләшә, бер яртыны матур гына сындыралар. Сәгать төнге бер була, ике була, инде өч тә җитә, ә Ркаил йокларга уйламый да. Шырт-пырт һаман йөреп тора. Тәмәкесен дә киләмгә басып кына сүндерә. Йокы яраткан Ахир Ркаилгә берничә мәртәбә кисәтү ясый. Дусты тыңламый. Тавыш чыга. Күршеләре милиция чакырта. Төнге дүрттә фатирга участок милиционеры килеп керә. Азәрбайҗан милләтеннән. "Без инде дуслаштык, китсәгез дә була", – ди аңа хуҗа. Ләкин участковый үз кирелеген итә – протокол язарга утыра. "Исемең ничек?" – дип сорый ул кунактан. "Гомәр", – дип җавап бирә Ркаил. "Фамилия?" – "Бәширов". – "Атаңның исеме?" Әйтер иде, Гомәр аганың атасының исемен белми. Ләкин аптырап та калмый: "Мин әтине сатмыйм!" – дип җавап бирә Ркаил.

## ОЗАК СӨЙЛӘШҮ ГАЛӘМӘТЕ


Журналист Айрат Садыйк белән шагыйрь Мөдәррис Әгъләм кичке Казан урамыннан баралар икән. Шунда боларга бер төркем Казан хулиганнары килеп бәйләнгән. Әгъләм качкан. Айраттан акча сораганнар. Тапмагач, моны каты итеп дөмбәсләгәннәр. Хулиганнар китеп баргач, куак арасыннан Әгъләм дә килеп чыккан. Аптырап калмаган:

– Авылдашлар булды, ахрысы, бигрәк озак сөләштегез! – дигән аңа Әгъләм.

Валентин ДУБИНИН



Игорь КИЙКО



Виктор ФЁДОРОВ



# ҮТКӘННӘРГӘ КАРЫЙК КАЕРЫЛЫП

Габдулла Тукай әсәрләре матбугатта беренче тапкыр 1905 елда гына басыла. Әмма аның язучылык эше белән бераз элегрәк шөгыльләнә башлаганлыгы мәгълүм. Ул 1903-04 елларда ук И. А. Крыловның күп кенә мәсәлләрен кыска-кыска хикәяләр рәвешендә тәрҗемә иткән.

Тукай белән бер мәдрәсәдә укыган Шәриф Каюмов истәлекләрендә (истәлек Фәннәр академиясенең кулъязмалар фондында саклана) Тукайның 1905 елга чаклы ук язган, ләкин матбугатка чыга алмаган түбәндәге шигырьләре китерелә:

**“Укыгыз, кызлар, укыгыз!**
**Күп хәлләрне белегез!**
**Остабикәләрне ташлап,**
**Мәктәпләргә керегез!**
**Муллалар, сезне укытмыйча,**
**Сезнең үзәккә үтәләр,**
**Мәдрәсәдә яшь егетләр**
**Сездәй кызны көтәләр.**
**Конфет ашаган акчагыз**
**Үз яныгызга калсын,**
**Иннек-кершән акчалары**
**Ваклап җыела барсын.**
**Шулай ваклап җыйсагыз да**
**Бер кесә алтын тулыр,**
**Тамчы-тамчы тамган судан**
**Тирән диңгезләр булыр”.**

• • •

“Туйга бардым мин бүген: эчтем кымыз,
Кеше бик күп, бүлмәбез булды тыгыз.
Күп эчелгән – шартлый язды корсагым,
Һич үкенмим, андый туй булмас тагын.
Итчеләр, тиречеләр бик күп иде,
Ит исе, тире исе аңкый иде.
Таз Сабир, Сучы Шакир, Күктәк Галим,
Чакырылган Мөрсәлим һәм Мөстәкыйм.
Бар да сөйли кайда нәрсә алганын,
Бу базарда күпме табыш калганын.
Шулкадәр туйдым тире, ит исенә,
Валлаһигазим, икенче бармамын”.


• • •

**“Мөгаллим Нурый**
**Зур чалма урый,**
**Халыкка тугры**
**Күренә, дусларым.**
**Мөгаллим надан,**
**Укымый калган,**
**Укыта ялган –**
**Аңла, дусларым.**
**Нурый да тугры –**
**Кыйшык торбадан**
**Төтеннәр тугры**
**Чыкса, дусларым.**
**Ватык та тишек**
**Тәрәзә, ишек,**
**Хәлфәсе кыйшык**
**Авыз, дусларым”.**



Виктор ИГНАТЬЕВ, «Чаян» № 23, 1974

– Ферманы пыяла бетоннан салабыз!




Лия БОЧКОВА, «Чаян» № 2, 1980

– Бу курчак түгел, ә минем кызым. Балалар бакчасына берничек тә урнаштыра алмыйм!

# ЧАЯН ШИФАХАНӘСЕ



• • •

– Доктор, сезнең алма диетасы миңа ярдәм итми!

– Сез алмаларны юасызмы соң?

– Әйе.

– Ә сез аларны юмыйча ашап карагыз...

• • •

Ике табиб сөйләшә:

– Мин бронхиаль астма белән авыручыга җылырак киенергә киңәш бирдем.

– Һәм?

– Ул киткәндә минем тунымны урлаган!







Владимир ЗУЕВ

# АЛТЫНЧЫ ПАЛАТА

Рәссам Мурашкин белән язучы Букашкин эчүчелектән арына алмый азапланып беттеләр. Аларга инде наркологның да ярдәме булышмый башлады, һәм болар икесе дә профессор Бухалкинның психиатрлар дәвалана торган хастаханәсенә килделәр. Профессор яхшылап караганнан соң, Мурашкин белән Букашкинны алтынчы палатага урнаштырды. Болар бу палатага кергәнче үк монда инде ике имгәк-сәрхуш яталар иде.

Палатадагы әлеге кешеләр бик ягымлы һәм культуралы булып чыктылар. Алар бер-берсенең исемнәренә әтиләренекен дә кушып, "кемович" дип кенә сөйләшәләр һәм профессорны да бик мактап, өзгәләнеп, яратып искә төшерәләр булып чыкты.

Ятуларына өченче көн киткәндә алкоголиклар палатада бишенче караватт барлыгын күрделәр. Шунда Букашкин, болар янына тагын берәүне, үзләре кебекне түгел, ә нинди дә булса психны кертергә мөмкиннәр икәнлеген сагаеп әйтеп куйды. Букашкинның бу фикере белән барысы да килеште. Чыннан да, хәзерге буталчык тормыштан әлләниләр көтәргә мөмкин.

Күп тә үтмәде, палатага утыз яшьләр тирәсендәге алагаем гәүдәле таза бер егетне керттеләр. Ул керү белән Букашкинга сәер генә итеп карады да, аңлап булмаслык сүзләр мыгырдады.

Рок-төркем җырчысы Ким Шаров иде бу. Менә шул авыр рок аны шундый кара уйлар һәм "белая горячка" хәленә китергә дә инде. Ким үзе дә берәр псих янына кертеп яткырырлар инде мине дип курыккан икән, бигрәк тә тешләкләрдән. Палатадагы ике ир аңа керү белән бик шикле күренде. Алар үзләрен тыныч тота, тик менә бер-берсенә сәер карашып алулары җанын борчый.

– Менә ниһаять чып-чынын китерделәр... – дигән сүз ычкындырды Мурашкин.

Ким, күршесенә әйләнгән Мурашкинның әллә ниләр сөйли башлавыннан сәерсенеп, профессорны чакыртырга боерды.

Көтмәгәндә палатадагылар барысы да коридорга ыргылды – алар яңа авыруны котырган, җәнҗал куптара дип уйлады. Профессор Бухалкин шундук бу мәсьәләне ачыклап аңлатты. Һәм алтынчы палатадагы яшәүчеләр Кимны үзләре кебек үк алкоголик дип таныды, аны туганнары итеп күрә башлады. Авыруга зур игътибар, хөрмәт күрсәттеләр, ә Ким, аларга җавап йөзеннән, әле моңа кадәр беркайда да, беркемнән дә мондый кадер-хөрмәт тоймаганын әйтте.

Шушы мәшәкатьләрдән соң профессорның эш сәгате тәмамланды, һәм ул автобус тукталышына чыкты. Тукталышта унлап кеше басып тора. Шуларның икесе автобус билетларының бәясен күтәргән өчен шәһәр башлыгын эт итеп сүгә иде. Ә берсе чүп савыты артына беркемгә дә игътибар итмичә, тыныч кына пес итә. Янәшәдәгеләр дә аңа бер сүз әйтми, чөнки алар ике хатын-кызның чәчләрен йолкый-йолкый сугышканнарын карап торалар. Шау-шу, кычкырыш, чинаш, сүгенү – ни өчен сугышалар, сәбәбе нидә – кем белгән? Профессор, үзенә тия күрмәсеннәр тагы, дип, читкәрәк барып басты. Урамдагы гади кешеләрдән нәрсә көтәргә мөмкин икәнлеген бик яхшы белә ул, чөнки боларның психик яктан чыннан да саусәламәт кешеләр булуына иманы камил, моны ул һич шикләнми әйтә ала.




## ӨЛЕШЕҢӘ ТИГӘН КӨМЕШЕҢ!

Хөрмәтле редакция! Авиатөзелеш районындагы ишегалларының торышын күрәсең килсә, күз сирпеп алу да җитә, һәм башка ишегаллары белән аерма әллә кайдан күренеп тора.

Әйтик, Лукин урамы 8 нче һәм 16 нчы йортлар арасында урнашкан ишегалдын алыйк. Балалар мәйданчыгы, ял итү өчен эскәмияләр белән дә тәэмин ителгән. Хәтта, машиналар да газонда түгел, махсус әйләндереп алынган мәйданга куелган. Бер ай дигәндә, Яшьләр урамы 14 нче "Б" йорты ишегалды да төзекләндерелде. Корыч койма белән матур итеп әйләндереп алган мәйданчыкта таган, балалар таучыгы, чәчәк клумбалары урнаштырылды.

Ә менә Максимов урамы 4 нче "А" ишегалды бары тик машиналар парковкасына әйләнеп калды. Балалар мәйданчыгын үткән гасырдан калган бердәнбер кыегайган таучык кына бизәп тора.

Кызык, ни өчен идарә итү компаниясенең берсе халык өчен тырыша, ә икенчесе юк? Бер карасаң, уңайлылык өчен барыбыз да тигез түлибез ич...

**Т. ИБРАҺИМОВ**

КАЗАН

## АВЫЛ КҮЛӘМЕНДӘГЕ "ПЛАТОН"

Кадерле Чаян! Соңгы хәбәрләрдән белгәнебезчә, ил күләмендә авыр йөк машиналары өчен түләү – Платон" системасы кертелә башлады. Янәсе, җыелган акчага юлларны төзекләндерәчәкләр икән. Әлеге темага бәхәсләр куерган арада, безнең авылда "Платон" системасы эшли дә башлады. Дөрес, бераз җиңеләйтелгән вариантта.

Авылның йөзек кашы булган үзәген еш кына зур йөк машиналары изеп бетерә. Берничә ел эчендә юллар, тәмам эштән чыгып, яраксызга әйләнә. Әлеге юлларны төзекләндерергә бюджет акчасы юк һәм якын арада күренми дә. Авыл администрациясе берничә мәртәбә зур йөк машиналары оешмасына намусларына оят булмас микән дигән үтенеч белән мөрәҗәгать итеп карадылар, ләкин җавапка юл такмаклары гына ишеттеләр...

Ни эш кылырга белмичә аптыраган авыл халкы башлыгы юлны үз машинасы белән каплап куйды. Акча бирмиләр икән – юл да юк!!! Башлык машинасын юлдан кузгатырга берәүнең дә кыюлыгы җитмәде. Хәзер исә авыр йөк машиналары безнең авылны урап, бата-чума торганнардан узалар...

**Азнакай районы ЧЕМОДУР авылы халкы**

ТАТАРСТАН

Валентин ДУБИНИН











Иван АНЧУКОВ


Владимир ИЖБОЛДИН



Валентин ДУБИНИН

• • •

– Туташ, сезне чәйгә чакырырга мөмкинме?

– Мөмкин, ләкин яткач тартмаска!

• • •

Кыз дискотекадан кайтып керә. Әнисе ачулана:

– Нәрсә киеп йөрисең син танцыга! Тиз генә киен дә йокларга ят!

• • •

– Әйт әле, Интернетта кызлар белән ничек якынрак танышып була?

– Берәр җиргә алып бар үзен. Мәсәлән, берәр яхшы ресторан сайтына.



Виталий ФЕОКТИСТОВ



ЧуАр пресса

### «М» һәм «Ж» класс

Финляндиянең Премьер-министры Юха Синияга ашыгыч рәвештә Хельсинкидан Оула шәһәренә очарга кирәк була. Самолётта бары бер генә урын буш икән. Түрә бу урынны үз хатынына бирә, ә үзе очу вакытын бәдрәфтә утырып чыга. Хөкүмәт башлыгы шулай итеп тынычлыкта кәгазьләр белән эшләргә җайлы урын тапкан.

### МӘХӘББӘТ

22 яшьлек Томск шәһәрендә яшәүче берәү буйдак тормышы белән саубуллашырга исәпләгән. Аны ЗАГСка кертмәгәннәр, шуңа күрә туй йоласы кафеда уза. Үтенечне кире кагуның сәбәбе – яшь егетнең пиццага өйләнүе. Бу хәл ират йөрәгенә юлның ашказаны аша булуын тагын бер тапкыр дәлилли.

### КИНДЕР-СЮРПРИЗ

Массачусетс штатында яшәүче Джуди Браун эч авыртуына зарланып, хастаханәгә мөрәҗәгать иткән. Табиблар, шаккаткан 47 яшьлек ханымны бала табарга вакыт җитүе белән шатландырган. Бер сәгатьтән Джудиның сәламәт кызы туа. 22 яшьлек ире гаиләләрендә мондый артым булачагын күз алдына да китерә алмаган.



Виктор ФЁДОРОВ




Заһир ХӘКИМОВ



## РЕКЛАМА

2016 елның беренче яртыеллыгына язылу башланды.

Журналның язылу индекслары татар телендә – 73488, рус телендә – 73489




Интернетта безнең сайт: chayan.su



Курт МЕНКЕЛЬ (Германия)




Корен Шамди (АКШ)

Чит ил карикатурачыларының рәсемнәре.

Тим ОБРАЙЕН (Англия)



Павел КУЧИНСКИ (Польша)






1913 ел:

– Кадерлем, мин әйтеп бетергесез соклангычта! Сезнең әдәби бөеклегегез мине шаккаттырды; ул акыллы, нәфис, нечкә хисләргә төрелгән, күпкырлы, һәм, ынашып әйтә алам, кабат укыган очракта ул тагын да матуррак төсләр белән яктыртылачак, сезне гаҗәеп куанычлы, озын һәм бәхетле язмыш көтүе турында әйтеп тормасаң да була!

2013 ел:

– Гы :) +100! Пешы исчо!

• • •

Футболчылар судьяның сатып алынганын сизә башлады, чөнки алар капкасына өченче пенальти билгеләнгәч, ул аны үзе тибәргә булды.

• • •

Халык ике генә нәрсә тели. Беренчесе: илдә бернинди дә ришвәтчелек булмауны. Икенчесе: бик арзанга гына теләсә нинди законны әйләнеп үтү мөмкинчелегe булуны.

• • •

Операциядән соң хирург авыру янына палатага кергән.

– Доктор, әйтегез әле, мин җенси мөнәсәбәтле тормыш алып бара алырмынмы?

– Хм, миндалинарын алган пациенткалар беркайчан да мондый сорау биргәннәре юк иде әле...

• • •

Рәсәйдә регионнарны финанслауның яңа ысулы эшли башлады: губернатор билгелиләр, аңа бер-ике миллиардны урлау мөмкинчелеге тудыралар, шуннан соң аны кулга алалар, конфисковать ителгән мөлкәтен регион мәнфәгатьләренә күчерәләр. Шулай итеп, икенче губернаторны кулга алганчыга кадәр.

• • •

Мәктәп укытучысы үзенең коллегасына сөйли:

– Әйбәтләп эшләргә бернинди мөмкинчелек калмады! Укытучы директордан курка. Директор – инспектордан. Инспектор – министерстводагы тикшерүчеләрдән. Министр – ата-аналардан. Ата-аналар балаларыннан курка. Балалар гына беркемнән дә курыкмыйлар...

• • •

Һәр ел ниндидер хайван елы булганда, кеше сыман ничек яшәп булсын...



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

(СКОРПИОН)

1923 елдан чыга.

№ 23 (1835) 2015

**«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры һәм баш редактор Рафаэль ХӘЛИЛУЛЛОВ**

Баш редактор урынбасары: Ринат АБЗАЛОВ

Баш редактор урынбасары, баш рәссам: Александр АЛЁШИН

Үсеш бүлеге: Әдилә БАҺАВЕТДИНОВА

Марс САБИРОВ

Җаваплы секретарь: Гөлнара ЗАМАЛДЫНОВА

Бүлек редакторлары: Людмила САФИУЛЛИНА

Артём СУББОТКИН

Алмаз ХӘМЗИН

Лилия ӘХМӘТОВА

Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

Дизайнер: Ләйсән ФӘЛӘХОВА

**УЧРЕДИТЕЛЕ: «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.**

Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итүче Федераль служба (Роскомнадзор) идарәсендә теркәлде.

**Теркәлү саны һәм вакыты: ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.**

Нәшер итүче: **АО «ТАТМЕДИА»**

Адрес: 420047 Казан, Академическая ур., 2

**«Чаян»га Татарстанда, Россиядә һәм БДБда барлык элемтә бүлекчәләрендә һәр айдан язылырга мөмкин.**

**ТАТАРЧА «ЧАЯН»НЫҢ ИНДЕКСЫ – 73488, РУСЧАСЫНЫКЫ – «ЧАЯН» («Скорпион») – 73489.**

Айга ике тапкыр чыга.

***Редакция фикере авторлар фикере белән тәңгәл килергә мөмкин.***

**Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.**

**Реклама белдерүләренең дөреслеге өчен реклама бирүче җаваплы.**

Басма 16 яшьтән өлкәнрәк укучылар өчен чыгарыла.

«Чаян»нан икәнен күрсәтмичә журнал әсәрләрен файдалану тыела.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.

Басарга кул куелды: 9.12.2015 ел.

Гомуми тираж – 3388 (рус. – 1974, тат. – 1414)

Заказ О- 3503

Кәгазь форматы 84х108 1/16.

Офсет ысулы белән басыла.

Басма табагы 2,1.

Учетн.-изд. табагы 3,1.

Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-06-00,

татмедиа тел./факс: 222-05-54.

16+

E-mail: chayan@bk.ru

Сайт: chayan.su

Редакциянең адресы: Декабристлар ур., 2, ТР, Казан, 420066

Бәясе ирекле

Алмаз ХӘМЗИН

ТУКАЙ ӘЙТКӘННӘРГӘ КОЛАК САЛЫЙК

# “ТӘНКЫЙТЬ – КИРӘКЛЕ ШӘЙДЕР”

“Китап, газета вә журналларны соратучы халкыбызның күбесе кара халык булганга, аларның да ләззәтләнә вә тәм таба торган нәрсәләре түбән вә тупас нәрсәләрдер. Әгәр газета вә журналлар таратуда гүзәл нәтиҗәләргә ирешик дисәләр, билгеле, аларга да түбән дәрәҗәле, тупас нәрсәләр язып, “мөхтәрәм сатып алучыларның зәвекъләренә иярергә кирәк буладыр. Мин үзебезнең арабызда бер журнал, бер газета беләмен ки, болар, тәмам-тәмам шул “мөхтәрәм сатып алучылар”ның теләкләренчә, әдәп таптап, яхшы ук баеп вә файдаланып торалар. Бәлки, алар, үзләренчә, милләткә файда итәбез ди торганнардыр: анысы табигый инде. Менә инде шул матбугатта аз булса да хөрриятне урынсыз файдаланмасак, бәлки, эшебез алга китәр иде”.

Мин бу фикерләрдән әллә ни тайпылмыйча, үз заманыбызда китап, журнал, газета таратуда зур тәҗрибә туплаган кеше икәнлегемне белдереп, Тукай күзәтүләре белән тулысынча килешеп, уртак нәтиҗә ясамак булам.

Әйтерсең лә бу вазгыять, ягъни матбугатка мөнәсәбәт шул вакытлардан бирле тамчы да үзгәрмәгән. Шундый ук цензура яшәп килә, туры сүзгә һәм дөрес фикергә сусау нык булса да, аңа матбугатта урын юк, күбесенчә гайбәткә ихтирам күрсәтү күзәтелә; төрләр тәнкыйть утына дучар ителсәләр дә, “өстән”рәк күрсәтмә бирүче даирәләр тарафыннан үч алу максатында гына бу эш башкарыла, ягъни заказлы материал бастырыла. Гади укучы моны дөреслекнең җиңүе дип таный. Ә хакыйкатьнең бөтенләй башкача булганлыгы вакыт үтү белән раслана.

Аннан соң әдәбиятыбыз ипсез сүзләр белән чуарлана бара. Әлбәттә, шулар белән “матур”ланган әсәрләрне “әдәбият” дип тә әйтеп булмый, “әсәр” дип әйтүгә дә шик тотам. Мондый очсыз юнәлешнең максатын мин чамалыйм – бу төрләрнең дөрес булмаган кыланмышыннан читләштерү юлының иң уңайлы төре. Демократия уйнаган булып кылану, илдә теләсә нәрсә эшләп маташкан булу – ул бит әле рәхәт яшәү дигән сүз түгел. Болай яшәүне бервакыт туктатырга кирәк булачак – монысы көн кебек ачык. Икътисад һәм сәясәт үз агымы белән бара алмый. Аңа дөрес юнәлеш бирүче идеология салынуы мөһим. Кешеләрне чын Кеше итеп тәрбияләү зарур. Ә моңа бары тик әдәбият һәм сәнгать аркылы гына ирешү мөмкин. Милләтне дә Зур Милләт итүче – укымышлылык, гыйлемлелек. Бу мәсьәләдә без бик мактанабыз, әмма хакыйкатебез башкачарак...

Мәктәпләрдән башлыйм. Миңа соңгы алты ел эчендә 600 гә якын республикабыз һәм чит төбәк мәктәпләрендә, язучы һәм артист буларак, 600 очрашу оештырырга туры килде. Мин бу эшне үземнең туры вазыйфам дип кабул итәм. Әйе, язучының иң төп бурычы халык белән тыгыз элемтәдә тору. Үзем белән, гадәттә, балалар укысын өчен “Казан утлары” һәм “Сабантуй” журналларын, аннан язучыларыбызның әһәмияткә ия китапларын алып барам, аларны китапханәләренә, балаларның үзләренә таратам. Игътибарга һәм хөрмәткә лаек гамәлме? Һичшиксез! Мактанып торасым килми, очрашулардан соң укучыларның шат йөзләрен күрү өчен барыгызның да әлеге мизгелгә килеп каравыгызны хуп табар идем.

Тагын бер мисал. Күптән түгел мин “Чаян” журналын пропагандалау чарасы ясап, Казан тирәсендәге бер районның шактый гына зур авылында булдым. Гадәттә, үзем белән, җыелган халыкка бүләккә дип, Казан киоскларында сатылмый – кире редакциягә кайткан журналларны алып барам, һәм аларны тамашачыларга таратам. Концертыма почтальонны чакыртам, ул тамашага килүчеләрнең 150 сумына “Чаян” журналына язылу квитанциясе биреп тора, ә мин, шуннан соң, үземнең аппаратура белән ике сәгатьлек концерт куеп, күңелләрен ачам. Шәпме? Шәп! Минем кесәгә бер тиеннәре дә керми, хәләл концерт куюым үз журналым – “Чаян” өчен, халкым өчен, алар укымышлы булсыннар өчен! Ә тамашачыларымнан рәхмәт сүзләре генә ишетәм.

Искәрмә: шул концерттан соң берәү, миңа төрттереп, димме, әллә минем хәлемә керепме:

– Әкият сөйлим әле сиңа, Алмаз, тыңла! – диде. – Яшәгән, ди, бер Җырчы Кырмыска. Ул бик мәрхәмәтле булган, синең төсле үз халкына мәгърифәт вә аң өләшеп, җырлап йөргән.

Шул заманнарда, кырмыска халкының кислотасына туена алмыйча, аларның өнен тузгытып йөрүче җырчы Аждаһа да яшәгән. Тамагы ачкан саен, килә дә икән, акырып җырлап, кислоталарын җыеп китә икән. Кислота, кырмыска халкы өчен – яшәү чыганагы.

– Йә, абзый, читләтеп сөйләп торма, Аждаһаның кем икәнен аңладым, күпме “кислотагызны” сыкты соң ул?

– Әйтмим, ишетсәң йөрәгең тибүдән туктар...

– Рәхмәт. Мине хөрмәт итәсең, ә аңа түлисең...

– Түләми кара!..

Берәү дигәнем, мин килгәнче – атна элек “өстән” йөкләтелеп килгән җырчы турында сөйли булып чыкты абзый кеше. Менә сиңа кирәк булса: берәүләребез мәгърифәт дип, ә икенчеләребез кесә калынайтып йөрибез икән ләбаса.

# Карикатура осталары

## Найджел БЬЮКЭНЭН (Австралия)





Ерак Австралия рәссамнарының карикатура темалары безгә бик якын икән. «Яшел континент»та яшәүче Найджел БЬЮКЭНЭН рәсемнәре моның ачык дәлиле булып тора.







